ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru


**КАРАР**
**6 декабрь 2019 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 340**

**“Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү һәм аның составына керүче “Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәшлеге” мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында**

“Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү һәм аның составына керүче “Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән алар составына керүче торак пунктларны башка муниципаль берәмлекләр территориясенә кертүгә китермәгән чиктәшлеге мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре белән эш йөртеп, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12, 14, 28 статьялары һәм “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында”, 2018 елның 28 мартындагы 209 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы,

К А Р А Р   И Т Т Е:

1. “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртүне һәм аның составына керүче “Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән алар составына керүче торак пунктларны башка муниципаль берәмлекләр территориясенә кертүгә китермәгән чиктәшлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе нигезендә, әлеге карарны “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү һәм аның составына керүче “Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән алар составына керүче торак пунктларны башка муниципаль берәмлекләр территориясенә кертүгә китермәгән чиктәшлеге мәсьәләсе буенча халык фикерен ачыклау өчен Казан шәһәре администрациясенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән бәйләнешләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин